**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 октября 2020 г № 397

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакындагы карары

Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү максатынан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының хезмәт өчен түләү чыгымнары күләмен билгеләү методикасының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында " 2020 ел, 16 октябрь, 935 нче карары нигезендә, гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итүТатарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 596 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне

формалаштырганда исәпкә алына торган мәсьәләләр турында Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1.Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә районы Башкарма комитетының 2018 елның 8 февралендәге 29 номерлы карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль бервмлек учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең 6 пунктына үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://atnya.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә уземэ калдырам.

Җитәкче А. Ф. Каюмов

Татарстан Республикасы
Әтнә районы башкарма комитетының
2020ел 22 октябрендәге 397 номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитетының 08.02.2018 елгы, №29 карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең 6 пунктына үзгәреш

6. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары 1 нче таблицада китерелгән.

Таблица 1

| № п/п | Хезмәткәр вазыйфасы | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Оешма Җитәкчесе | 7724,00 |
| 2 | Оператив дежур | 7028,00 |